Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Иске Камка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы карары белән кабул ителде
2025 елның «08» августы № 118

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы**
**«Иске Камка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге Уставына Үзгәрешләр**
**һәм өстәмәләр кертү турында**

Иске Камка ав.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Старокамкинского сельского поселения
Алькеевского муниципального района

Адресы: 422897, ТР, Әлки районы,
Иске Камка авылы, Түбән урамы,1 йорт
тел./факс 8(84346) 73-524

Адрес: 422897, РТ, Алькеевский район, с. Старое Камкино, ул.Нижняя
тел./факс 8(84346) 73-524

РЕШЕНИЕ Иске Камка ав. КАРАР

2025 елның " 08 " августы № 118

Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 23.10.2023 елның 70-нче номерылы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Иске Камка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында " карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы Прокуратурасының хокук булдыру инициативасын өйрәнеп, муниципаль берәмлек Уставының 85,86 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 23.10.2023 елның 70-нче карары белән (29.07.2024 елның 91-нче карары редакциясендә) 1 нче кушымта нигезендә расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Иске Камка авыл җирлеге

территориясендә: Татарстан Республикасы, Әлки районы, Иске Камка авылы, Түбән Кама ур., 1 (җирле үзидарә бинасы), Иске Камка авылы, Үзәк урам, 38 А йорт (авыл мәдәният йорты) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында (http://alkeevskiy.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
«Иске Камка авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Р.З.Әглетдинов

1 нче кушымта
Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
Советы карарына
08.08.2025 ел, № 118

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Иске Камка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19.1 пункт өстәргә:

"19.1" шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112 номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып барган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру".